ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР СУКСУЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

423736, Татар Суксуы авылы,
Гагарин ур.,1 б нче йорт.
Тел. 3-44-60
e–mail: tsuk-akt@yandex.ru

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТАТАРСКО-СУКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423736, с. Татарские Суксы,
ул. Гагарина, дом 1 б.
Тел. 3-44-60
e–mail: tsuk-akt@yandex.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**5 февраль 2026 ел** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Советының 2017 елның 07 сентябрендәге 22 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлегенең 2017 елның 07 сентябряндәге 21 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлегенең муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Суксуы авыл җирлеге Советының 25.06.2018 ел № 13. от 13.09.2018 ел № 25, от 15.02.2019 ел № 3, 23.09.2019 ел № 30, 23.01.2020 ел № 3, 12.10.2020 ел № 7, 27.02.2021 ел № 2, 14.07.2021 ел № 13, 21.06.2023 ел № 10, 14.07.2023 ел № 13, 04.04.2024 ел № 3, 24.10.2024 ел № 18, 18.12.2024 ел № 25 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 21 бүлектә:

**а) 1 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. Муниципаль хезмәт урынын биләргә дәгъва кылучы гражданин, муниципаль хезмәткәр эш бирүче вәкиленә (эш бирүчегә) 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы көрәш турында" Федераль законда каралган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматларны, әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда, тапшыра. Күрсәтелгән мәгълүматлар "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм формада тапшырыла.

б) **1_1 өлешне** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1_1. Муниципаль хезмәт урынын биләгән муниципаль хезмәткәр, тиешле исемлеккә кертелгән, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы "Дәүләт вазифаларын биләгән затларның һәм башка затларның керемнәренә туры килүче чыгымнарны контрольдә тоту

турында" Федераль законда каралган чыгымнар турында мәгълүматларны, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан шундый мәгълүматларны тапшыру тәртибе һәм формасы буенча тапшырырга бурычлы."

**в) 2 пунктта** "керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләр турында" сүзләрен төшереп калдырырга;

**г) 3 пунктта** «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган мәгълүматлар»,» сүзләренә алмаштырырга;

**д) 4 пунктта** "муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар" сүзләрен "муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге статья нигезендә тәкъдим ителә торган мәгълүматлар" сүзләре белән алыштырырга;

**е) 5 пунктта** "үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләре, шулай ук үзенең тормыш иптәше һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар" сүзләрен "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар һәм "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турында мәгълүматлар" сүзләре белән алыштырырга,

**ж) 8 пунктны** түбәндәге редакциядә бирергә:

"8. Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматларны, мондый вазыйфаны биләүче зат әлеге статьяның 1 һәм 1_1 өлешләрендә күрсәтелгән мәгълүматларны Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) тапшыралар»;

**з) 9 пунктны** үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 16 бүлекнең 16.3 пунктындагы 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10) "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Татар Суксуы авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе Г.Г. Хамматуллина